КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 май г.Казань № 324

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яки) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу куркынычы барлыкка килгәндә медицина оешмаларын өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда, Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яки) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу куркынычы барлыкка килгәндә медицина оешмаларын өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен тиешле территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау ту-

рында» 2021 елның 11 февралендәге 163 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яки) әйләнәтирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу куркынычы барлыкка килгәндә медицина оешмаларын өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондыннан заявка бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 11 май, 324 нче
карары белән расланды

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яки) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу куркынычы барлыкка килгәндә медицина оешмаларын өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен гамәлгә ашыру тәртибе

1. Бу Тәртип 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яки) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу куркынычы барлыкка килгәндә медицина оешмаларын өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт (алга таба шул ук эзлеклелектә – Фонд, бюджетара трансферт) бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

2. Фонд бюджетына бюджетара трансферт бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү 2021 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Бюджетара трансферт акчасын тоту Фонд тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

4. Фонд бюджетына бюджетара трансферт бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме (2021 елга федераль бюджеттан Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсен финанслашуның иң чик дәрәҗәсе мәгънәсен һәм төзәтү коэффициентын исәпкә алып) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = C + V + R - I,$$

монда:

C – 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорга Татарстан Республикасында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авырган һәм (яки) әлеге авыру белән авыруына шик булган затларга күрсәтелгән медицина ярдәменә (әлеге иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина

ярдәмен кертеп) түләүгә кабул ителгән счетлар буенча түләү өчен Фондка кирәкле акча күләме;

V – 2020 елның 1 мартыннан 31 декабренә кадәр «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы $8^1$ өлеше нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы Татарстан Республикасы медицина оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Фонд бюджетыннан җибәрелгән һәм әлеге медицина оешмаларыннан 2020 елның 1 мартыннан 31 декабренә кадәрге чорга Татарстан Республикасында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авырган һәм (яки) әлеге авыру белән авыруына шик булган затларга күрсәтелгән медицина ярдәменә (әлеге иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәмен кертеп) түләүгә кабул ителгән счетлар суммасыннан артып киткән акча күләме;

R – 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 5 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән максатлар өчен Фонд бюджетыннан җибәрелгән акча күләме;

I – 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешенең 1, 3, 4 һәм $6^1$ пунктларында күрсәтелгән Фонд бюджеты керемнәрен формалаштыру чыганаклары исәбеннән Фонд бюджетына кергән керемнәр күләме.

5. Фонд бюджетына бюджетара трансферт күчерү Фонд тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кертелә торган, акча күләмнәренең бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән керемнәр күләменнән артып китү күләмен раслый торган заявка нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бюджетара трансферт бирүгә заявка кергән көннән биш эш көне эчендә Фонд бюджетына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан әлеге бюджетара трансферт бирүгә кертелгән заявка нигезендә 2021 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгән иң чик финанслау күләмнәре чикләрендә бюджетара трансферт бирә.

7. Фонд:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан расланган форма буенча бюджетара трансферт бирүгә заявка җибәрә;

кергән бюджетара трансферт акчасын «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән максатларга Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Мәҗбүри медицина иминияте кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 28 февралендәге 108н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә җибәрә;

бюджетара трансферттан файдалану турында (шул исәптән бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү хакында мәгълүмат бирелгән) Федераль мәҗбүри медицина иминияте фондына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан билгеләгән формада, тәртиптә һәм срокларда хисаплылык тапшыра.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Фондтан бюджетара трансферт бирүгә заявка кергән көннән биш эш көне эчендә Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан расланган форма буенча бюджетара трансферт бирүгә заявка җибәрә;

түбәндәгеләрне Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында бюджетара трансферт бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасына кертә:

а) финанслар белән тәэмин итү максатларында бюджетара трансферт бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап;

б) бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында хисап.

9. Фонд тарафыннан максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган бюджетара трансфертлар, алга таба Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет кеременә күчерү максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

10. Бюджетара трансферттан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.